| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**13.03.2019** | Зеленодольск<br>шәһ. | **КАРАР**<br>**№ 627** |

2019 елда гражданнарның салым салынырга тиешле табышының һәм милек бәясенең чикләнгән мәгънәсен раслау турында

Татарстан Республикасының 2018 елның 7 ноябрендәге «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм социаль найм килешүләре буенча муниципаль торак фондыннан гражданнарга торак бирүдә аларның хокукын гамәлгә ашыру турында» Законына үзгәрешләр кертү турында» 85нче ЗРТ Законына ярашлы рәвештә һәм күрсәтелгән закон кушымтасында билгеләнгән салым салынырга тиешле ялгыз яшәүче гражданинның яисә гаилә әгъзаларының шәхси мөлкәтенә кергән милке бәясенең һәм ялгыз яшәүче гражданинга һәм һәр гаилә әгъзасына туры килгән табышының чикләнгән мәгънәсен билгеләү Методикасы белән, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 декабрендәге «2019 елның I кварталында Россия Федерациясе субъектлары буенча торак биналары гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» №822/пр Боерыгы белән, һәм шулай ук Торак кодексының 49нчы, 51нче маддәләренә нигезләнеп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. 2019 елда гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чикләнгән мәгънәләрен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзаларының (ялгыз яшәүче гражданинның) исемендәге салым салынырга тиешле мөлкәте бәясенең чикләнгән мәгънәсе:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 523 610 сум;
1.1.2.ике кешедән торган гаилә өчен – 1 939 140 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 493 180 сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 324 240 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 4 155 300 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 986 360 сум;
1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 817 420 сум;

1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килгән табышның уртача күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 28 528,52 сум;
1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 18 154,52 сум;
1.2.3. өч һәм аннан артык кешедән торган гаилә өчен – 15 561,02 сум.

2.«ЯҮМР торак сәясәте Департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә торак биналарга мохтаҗ буларак исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1нче һәм 1.2нче подпунктларында күрсәтелгән чикләнгән күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм СМИ белән элемтә буенча бүлек җитәкчесенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгаруны тәкъдим итәргә.

4. Карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

**2019 елда гаилә әгъзаларының һәм ялгыз яшәүче гражданинның мөлкәтендә булган салым салынырга тиешле милке бәясенең, һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданинга туры килгән табышының чикләнгән мәгънәсен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

1. **Базар бәясен исәпләү күрсәткече**

    **СЖ= НП*РС* РЦ, анда**

СЖ – базар бәясен исәпләү күрсәткече яисә милекнең чикләнгән бәясе;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак бина бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзаларының саны;

РЦ – РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы раслаган 1 кв.м. мәйданны уртача исәпләү базар бәясе (2019 елның беренче кварталында – 46 170 сум)

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен:

СЖ= 46 170 *33= 1 523 610

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *42= 1 939 140

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*3= 2 493 180

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*4= 3 324 240

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*5= 4 155 300

ж) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*6= 4 986 360

з) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=46 170 *18*7= 5 817 420

2. **Гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача бердәм табышының чикләнгән мәгънәсе**

**ПД=0,7*СЖ*ПС/ (1-(1+ПС)$^{-КП}$ ) / (0,3*РС), где**

СЖ – социаль найм килешүе буенча торак бина бирү нормасы буенча торак бина сатып алуның базар бәясен исәпләү күрсәткече;

ПС – бер айга кредит буенча процент ставкасы (7,75/12);

КП – кредитның бөтен срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны ( айлар саны);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы һәм квартир бәясе нисбәте;

0,3 – гаиләнең уртача айлык бердәм табышы белән кредит буенча түләү нисбәте;

а) ялгыз яшәүче гражданинга:

$ПД=0,7*1\ 523\ 610*0,0065 / (1-(1+0,0065)^{-250})/ (0,3*1)= 28\ 528,52$

б) ике кешедән торган гаиләгә:

$ПД=0,7*1\ 939\ 140*0,0065 / (1-(1+0,0065)^{-250} )/ (0,3*2)= 18\ 154,52$

в) өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләгә:

$ПД=0,7*2\ 493\ 180*0,0065 / (1-(1+0,0065)^{-250} )/ (0,3*3)= 15\ 561,02$

г) дүрт һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләгә:

$ПД=0,7*3\ 324\ 240*0,0065 / (1-(1+0,0065)^{-250} )/ (0,3*4)= 15\ 561,02$

«Зеленодольск муниципаль районы
торак сәясәте департаменты»
МКУ җитәкчесе Н.Н. Минһаҗев